**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

« 22 » ноябрь 2017 ел                                        № 51

**Җир налогы турында**

**1 Статья. Гомуми нигезләмәләр**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә әлеге кара Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирле территориясендә мәҗбүри булган җир салымы (алга таба – салым) билгеләнә һә гамәлгә кертелә.

**2 Статья. Салым ставкалары**

Салым ставкалары түбәндәге зурлыкта билгеләнә:

1) **0,3%** авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә торак пунктлардаг авыл хуҗалыгы куллану зоналары составындагы һәм авыл хуҗалыгы житештер өчен кулланыла торган җирләргә карата;

2) **0,3%** торак фонды һәм торак-коммуналь комплекс инженер инфраструктурас объектлары белән мәшгуль җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һә торак-коммуналь комплексның инженер инфраструктурасы объектларына керм торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокук өлешеннән тыш) яи торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата

3) **0,1%** шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек яки терлекчеле шулай ук дача хуҗалыгы өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата ;

4)**0,01%** Автоном учреждениеләрнең җир кишәрлекләренә; Татарста Республикасы бюджетыннан, Аксубай муниципаль районы бюджетыннан һә җирлек бюджетыннан финанслана торган бюджет учреждениеләренә, казь учреждениеләренә карата

5) **1,5%**башка җир кишәрлекләренә карата

**3 Статья. Салым ташламалары**

Салым салудан азат ителә:

оешмалар, учреждениеләр - гражданнар күмү белән шөгыльләнүче җир кишәрлекләренә карата

1-3 категорияле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен бирелә торган җир кишәрлекләренә карата 2 статьяның 5 пунктында (0,05 %) билгеләнгән 1/30 күләмендә салым ташламасын билгеләргә.

**4 Статья. Хисап чоры**

Календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы һәм өченче кварталы салым түләүчеләр-оешмалар өчен хисап чоры дип таныла.

**5 Статья. Салым түләү тәртибе һәм сроклары**

Салым түләүче оешмалар өчен салымны җир кишәрлегенең кадастр бәясене процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 өлеше күләмендә алдан түлә

башкарыла. Беренче кварталдан соң аванс түләүләрен түләү вакыты 10 майдан д соңга калмыйча, икенче кварталдан соң 10 августтан да соңга калмыйча һә өченче кварталдан соң, 10 ноябрьдән дә соңга калмыйча.

Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы үтка салым чоры артыннан баручы елның 10 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.

**6 Статья. Әлеге карарның үз көченә керүе**

Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма «Сельская новь " район газетасында рәсми басылып чыккан көннән соң бер айдан да иртәрәк чыкмый һәм Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырылырга тиеш

Әлеге карар үз көченә кергән көннән «җир салымы турында» 2008 елның 15 сентябрендәге 7 номерлы (2009 елның 26 ноябрендәге 15, 2010 елның 25 октябрендәге 6 номерлы, 2014 елның 10 ноябрендәге 14 номерлы, 2015 елның 20 октябрендәге 9 номерлы карар) карарны үз көчен югалткан дип танырга.

Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге
Совет Рәисе: Т.В. Зюзина